ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

КАРАР **РЕШЕНИЕ**

17 апрель 2019 ел **№ 283**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышу оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

«Экологик экспертиза турында» 1995 ел, 23 нче ноябрь, 174-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Россия Федерациясендә билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тәэсиренә бәя бирү буенча Нигезләмәне раслау турында» 2000 ел, 16 нчы май, 372 номерлы Россия Федерациясенең әйләнә-тирә мохит буенча Дәүләт комитеты боерыгы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышу оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин

Кушымта

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы Советы карары
белән
17.04.2019 № 283

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышу оештыру һәм уздыру тәртибе турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү максатларында, экологик экспертиза объекты булган, һәм аның әйләнә-тирәгә йогынты ясау мөмкинлеге, җәмәгатьчелекнең нәрсәгә өстенлек бирүен ачыклау һәм йогынтыга бәя бирү барышында аларны исәпкә алу максатларында Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафынаннан иҗтимагый фикер алышуларны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләрен җайга сала.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлек – әйләнә-тирә табигый мохиткә йогынты ясарга мөмкин булган экологик экспертиза объекты булып саналган эшчәнлек.

Билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү (алга таба - ОВОС) мөмкин булган тискәре йогынтыларны билгеләү, экологик нәтиҗәләрне бәяләү, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алу, йогынтыларны киметү һәм булдырмау буенча чаралар эшләү юлы белән күздә тотылган билгеләнгән хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында экологик юнәлешле идарә карарын кабул итүгә ярдәм итүче процесс.

Иҗтимагый фикер алышулар – әлеге Нигезләмә һәм башка норматив документлар нигезендә йогынтыны бәяләү кысаларында уздырылган билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү процессында аларны исәпкә алу максатында, башка эшчәнлек һәм аның әйлән-тирә мохиткә тәэсир итү мөмкинлеге турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итүгә юнәлтелгән чаралар комплексы.

Җәмәгатьчелек – билгеләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең экологик, социаль һәм икътисади нәтиҗәләре турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган рәвештә мәнфәгатьләренә кагылучы физик һәм юридик затлар.

Заказ бирүче – билгеләнгән эшчәнлек төренә карата куела торган норматив таләпләргә җавап биргән, билгеләнгән эшчәнлек буенча документларны әзерләү

буенча һәм билгеләнгән эшчәнлек төре буенча экологик экспертизага документлар тәкъдим итү өчен җаваплы юридик яки физик зат.

ОВОС буенча материаллар – билгеләнгән эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү уздыру барышында әзерләнгән һәм экологик экспертизага тәкъдим ителгән документларның бер өлеше булган документлар комплекты.

1.3. ОВОС материалларын әзерләгәндә җәмәгатьчелекнең катнашуы гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- беренче мәгълүмат тапшыру этабында;
- ОВОС үткәрү һәм нигезләү документларын әзерләү этабында.

1.4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә ОВОС буенча иҗтимагый фикер алышуларның предметы булып дәүләт экологик экспертиза объектының (алга таба - документлар) түбәндәге документлары тора:

- ниятләнгән эшчәнлекнең гомуми тасвирламасын үз эченә алган дәлилләүче документлар; аны гамәлгә ашыру максатлары; мөмкин булган альтернативалар; аны гамәлгә ашыру шартлары тасвирламасы; гамәлдәге норматив документлар белән каралган башка мәгълүмат;
- беренчел ОВОС нәтиҗәләре;
- ОВОС үткәрү өчен техник бирем;
- дәүләт экологик экспертиза объектларына куела торган, законнарда билгеләнгән таләпләргә туры килә торган ОВОС буенча материалларның башлангыч варианты.

1.5. Иҗтимагый фикер алышулар түбәндәге формада үткәрелә:

- җәмәгать тыңлаулары;
- сораштыру;
- ОВОС материаллары белән танышу, искәрмәләр һәм тәкъдимнәр күрсәтү.

ОВОС буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халык турыдан-туры хәл иткән очракларда җирле референдум “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.

1.6. Иҗтимагый фикер алышулар аларны үткәрү кирәклеге турында түбәндәге субъектларның берсе генә булса да белдерсә (алга таба – инициаторлар) үткәрелә:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгы;
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы;
- Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет);
- заказчы;
- мәнфәгатьләре турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган экологик экспертиза уздырылырга тиешле планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә кагылган юридик затлар һәм (яки) шәхси эшмәкәрләр;
- иҗтимагый фикер алышулар уздырылган көнгә 18 яше тулган һәм Биектау муниципаль районы территориясе чикләрендә яшәүче, 10нан да ким булмаган кеше торган гражданнарның инициатив төркеме;
- территория буенча эшчәнлек өлкәсе Биектау муниципаль районы территориясендә таралыш алган иҗтимагый оешмалар һәм берләшмәләр.

2. Иҗтимагый фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе

2.1. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы булып Башкарма комитет тора.

2.2. Инициатор Башкарма комитетка гариза, шулай ук иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү буенча эшче төркемгә (алга таба – эшче төркем) кертү өчен инициатордан вәкилләр исемлеген тәкъдим итә.

2.3. Әгәр инициатор булып заказ бирүче торса, гаризага Нигезләмәнең 1.4. пунктында күрсәтелгән документлар теркәлә.

2.4. Әгәр инициатор Башкарма комитеты булса, гариза бирү таләп ителми.

2.5. Оештыручы:

- гаризаны карый һәм заказчы тәкъдим иткән документлар составының Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килүен Башкарма комитетта документ теркәлгәннән соң 5 эш көне эчендә тикшерүне гамәлгә ашыра;

- иҗтимагый фикер алышуларны оештыру очрагында, инициатор белән берлектә үткәрү датасын һәм вакытын билгели;

- бина бирүне оештыра һәм иҗтимагый фикер алышулар барышында, материалларны язу һәм күрсәтү өчен аудио- һәм видеоаппаратура куллану, заказчы биргән кирәкле мәгълүмат материалларын күрсәтү мөмкинлеген тәэмин итә;

- әлеге Нигезләмәнең 2.7 пункты нигезендә Башкарма комитет Карары проектын әзерли;

- фикер алышу өчен чыгарыла торган мәсьәләләр буенча махсус белемнәре булган (алга таба – экспертлар) затлар исемлеген билгели; иҗтимагый фикер алышуларга кадәр аларга чакыру һәм тәкъдимнәр бирү үтенече белән мөрәҗәгать җибәрә;

- җәмәгатьчелек вәкилләренең документларга үтемлелеген тәэмин итә;

- хәбәрнамә басылып чыккан вакыттан алып 30 календарь көн эчендә җәмәгатьчелек вәкилләреннән килгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итүне һәм документлауны, заказчыга искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне кертүне тәэмин итә;

- әлеге Нигезләмәнең 2.10 пункты нигезендә иҗтимагый фикер алышуларны үткәрүне оештыра.

2.6. Заказ бирүче:

2.6.1. массакүләм мәгълүмат чараларында иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамә бастырып чыгаруны аларны үткәрүгә кадәр кимендә 30 календарь көн эчендә тәэмин итә (алга таба – язмалар).

Язмаларда түбәндәгеләр турында мәгълүматлар тәкъдим ителә:

- билгеләнгән эшчәнлек исеме, максатлары һәм урнашкан урыны;

- заказчы яки аның вәкиленең исеме, адресы, телефоны;

- ОВОСларны үткәрүнең якынча сроклары;

- заказчының исеме, адресы, телефоны;

- иҗтимагый фикер алышу формасы, шулай ук искәрмәләр һәм тәкъдимнәр тапшыру формасы;

- документларның үтемлелеге сроклары һәм урыны;

- башка мәгълүматлар.

2.6.2. язмаларның күчермәләрен оештыручыга җибәрә;

2.6.3. эшче төркем эшендә катнашуны тәэмин итә.

2.7. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү турындагы карар Башкарма комитет

карары рәвешендә кабул ителә, анда түбәндәгеләр билгеләнә:

- иҗтимагый фикер алышуларны оештыру өчен нигез;
- эшче төркем составы;
- әлеге Нигезләмәнең 1.5 пункты нигезендә иҗтимагый фикер алышу формасы;
- иҗтимагый фикер алышулар уздырылган очракта – үткәрү датасы, вакыты, урыны, тәртибе;
- тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшыру сроклары һәм урыны.

Башкарма комитет карары имза куелган көннән соң 10 календарь көн эчендә массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылып чыгарырга тиешле.

2.8. Эшче төркем комиссия рәисеннән, сәркатибеннән, инициатордан, оештыручыдан, экспертлардан һәм башка әгъзалардан тора.

2.9. Эшче төркем:

- иҗтимагый фикер алышуларының көн тәртибен әзерли;
- иҗтимагый фикер алышу нәтиҗәләрен билгели.

2.10. Иҗтимагый фикер алышуларны үткәрү тәртибе:

2.10.1. Эшче төркемнең рәисе (яки алып баручысы):

- иҗтимагый фикер алышуларны ача;
- эшче төркем әгъзаларын игълан итә;
- җәмәгать фикер алышуларын үткәрү тәртибен һәм фикер алышуларда катнашучыларның чыгыш ясау вакыты турында игълан итә.

2.10.2. Заказ бирүче яки аның вәкиле дәүләт экологик экспертиза объекты турында кыскача гына доклад бирә.

2.10.3. Оештыручы кызыксынган җәмәгатьчелек вәкилләреннән кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне укый.

2.10.4. Экспертлар, катнашучылар тема буенча искәрмәләр, тәкъдимнәр белән чыгыш ясыйлар, сораулар бирәләр, заказ бирүчеләрдән кергән сорауларга җаваплар алалар.

Чыгыш ясар алдыннан, иҗтимагый фикер алышуларда катнашучы үз фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, чыгыш ясаучы нинди дә булса оешманың вәкиле булса вазый фасын хәбәр итәргә тиеш.

2.10.5. Алып баручы (яисә эшче төркем рәисе) иҗтимагый фикер алышуларның төп нәтиҗәләрен ясый, җәмәгать фикер алышуларының беркетмәсен әзерләү тәртибен аңлата, аңа имза кую, искәрмәләр бирү тәртибен аңлата.

2.10.6. Иҗтимагый фикер алышулар беркетмәсе эшче төркем сәркатибе тарафыннан алып барыла һәм фикер алышуларда катнашучыларның чыгышлары бәян ителә (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен күрсәтеп), сораулар һәм җаваплар, карар тавыш бирүдә кабул ителгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр мәҗбүри тәртиптә объект заказчысы, эшче төркем рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана. Беркетмә иҗтимагый фикер алышулардан соң 5 эш көне эчендә төзелә һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

2.11. Гражданнардан һәм иҗтимагый оешмалардан билгеләнгән хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында карар кабул ителгәнчегә кадәр язма искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү, әлеге тәкъдимнәрне ОВОС материалларына кушымталарда документлаштыру заказчы тарафыннан җәмәгать тикшерүе тәмамланганнан соң 30 календарь көн эчендә тәэмин ителә.